СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Куркачи, ул.Клубная, 4

422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы, Клуб ур.4

Тел./факс: +7(84365) 70-7-00, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22 апрель, 2021 ел** **№ 26**

**Иске Казан авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Иске Казан авыл җирлеге территориясендә Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Иске Казан авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Иске Казан авыл җирлеге территориясендә Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 статьяда:

а) өченче абзацны «, әлеге статьяның дүртенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәп тулыландырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле дүртенче яңа абзац белән тулыландырырга:

«Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»;

в) дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларны тәңгәл рәвештә бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга;

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Закирова